## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында
2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2021 елның 18 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә I төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан кала, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Дружба авылы зират территориясе янындагы күперне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Дружба авылы өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлар сатып алу

-Ләке авыл җирлегендә “Питрау” бәйрәме уздыру өчен призлар, бүләкләр алу .

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә,Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче ________________ Шәрипова Л. И.